

*

“Юлда йөрсәң, бул өлгер,
Юл кагыйдәсен нык бел!”

* 1. Табышмаклар

Барам, барам,
очы юк.

* Дүрт дөбердек, ике елтырык, бер ыҗгырык.

* Ике аяклы үгез, маңгаенда куш мөгез

* Җәен, көзен, яз, кышын, иртән, кичен, көндезен
Ача, йома өч күзен, телсез әйтәдер сүзен,
Бик тиз аңлыйлар үзен.

* Сорау миннән, җавап сездән



# * 1 нче командага

1.Автобус көтү урыны.

2.Җәяү йөрүче кем дип атала?

3.Светофорның ничә төсе бар?

4.Машина юлы аша ничек чыгарга?

5.Велосипедта ничек йөрергә ярамый?

6.Җәяүлеләр өчен яшел ут янса, машиналар өчен нинди төс янар?

7.Җәяүле юлы.

8.Автобусны ничек әйләнеп узарга?

9.Нинди транспорт төрләре бар?

10.ЮХИДИ ничек була?

* 1.Автобус көтү урыны. (тукталыш)
2.Җәяү йөрүче кем дип атала? (җәяүле)
3.Светофорның ничә төсе бар? (3)
4.Машина юлы аша ничек чыгарга? ( зебра аша, .....)
5.Велосипедта ничек йөрергә ярамый? (кулны җибәреп)
6.Җәяүлеләр өчен яшел ут янса, машиналар өчен нинди төс янар?( кызыл)
7.Җәяүле юлы.( тротуар)
8.Автобусны ничек әйләнеп узарга? (арттан)
9.Нинди транспорт төрләре бар? (Су, һава, коры җир транспорты)
10.ЮХИДИ ничек була? (Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе)

# * 2 нче команда

1. Ничә яшьтән юлда велосипедта йөрергә ярый?
2. Автобус көтү урыны.
3. Транспортта баручы ничек атала?
4. Зебра ничә төсле?
5. Трамвайны ничек әйләнеп узарга?
6. Трамвай кайдан йөри?
7. Светофор ни өчен кирәк?
8. Транспорт белән идарә итүче.
9. Велосипедта кемнәрне утыртып йөрергә ярый
10. Светофорда кызыл сигнал кайда урнашкан?

* 1. Ничә яшьтән юлда велосипедта йөрергә ярый? ( 14)
2.Автобус көтү урыны. (тукталыш)
3.Транспортта баручы ничек атала? (пассажир)
4.Зебра ничә төсле? (2)
5. Трамвайны ничек әйләнеп узарга? (алдан)
6.Трамвай кайдан йөри? ( рельстан)
7.Светофор ни өчен кирәк? ( юлдагы хәрәкәтне көйләр өчен)
8.Транспорт белән идарә итүче. (шофер, транспорт йөртүче)
9.Велосипедта кемнәрне утыртып йөрергә ярый (кеше утыртып йөрергә ярамый)
10. Светофорда кызыл сигнал кайда урнашкан? (иң өстә)


# “Юл билгеләрен таны”











# * “Кем зирәк?”

1.Автобус туктагач, аны ничек әйләнеп чыгарга икәнен беләм:

а) читтән б) алдан в) арттан

2. Трамвайдан төшкәч, аны кайсы яктан урап үтәргә икәнен беләм:

а) нәкъ автобустагы кебек б) белмим в) алдан

3. Җәяүлеләр юл аша чыга торган урын:

а) жираф б) тротуар в) зебра

4. Юлны аркылы чыгар алдыннан нишләргә кирәк:

а)сул иңбаш аша төкерергә б) башта- сулга, аннан уңга карарга

в) башта- уңга, аннан сулга карарга.

5.Юл аркылы велосипед белән ничек чыгарга кирәк?

А) велосипедның руленнән тотып б) велосипедка утырып

# *Кемнең хәтере яхшы?










* Рәсемдә ничә кисәтү билгесе бар иде?

# *Кемнең хәтере яхшы?







* **Ничә очракта балалар кагыйдәне бозалар?**

* Зур теләк белән өйрән син,
Өлкәннәрне карап тор.
Машина узганын көтми-
Йөгермә син тизрәк.
Моны белү һәр балага,
Кайда йөрсә дә кирәк.



*Уйла

“Юадл йөңәср , өлрег луб, юл канесәдйыг кын леб!”

* “ Юлда йөрсәң, бул өлгер, юл кагыйдәсен нык бел!”



* “ Сабантуй” газетасының “ Хәерле юл!”сәхифәсенә ничә яшь?
  Сез аны һәрдаим укып барасызмы?

# *Уйнап алыйк

Сүзлек запасын арттырабыз

Аббревиатура – сүзтезмәнең беренче хәрефләрен кыскартып язу

Мәсәлән: АКШ – Америка кушма штатлары

ВАЗ – Волга автомобиль заводы

# 1 нче командага

ЮХИДИ


*ЮХИДИ - **юл хәрәкәте иминлегенең дәүләт инспекциясе**

* **2 нче командага**

ГИБДД

* ГИБДД - государственная инспекция безопасности дорожного движения

# *Юл аша чык



- 1 адым артка

- урыннарда калабыз

- 1 адым алга


# *Халык әйтемнәре

Әкрен барсаң – тизрәк барып җитәрсең.

Озак җиккән – тиз барып җиткән.

# *Уйнап алыйк

Машина төзе



# *Исеңдә тот!

- Җәяүле тротуардан гына, анда да уң яктан барырга тиеш ;

- тротуар булмаган очракта, юлның сул ягыннан, килгән транспортка каршы барырга кирәк ;

- юл аркылы бары тик рөхсәт ителгән җирдән генә чыгарга ярый ;

- юл аша чыкканда башта сулга, уртасына җиткәч уңга кара ;

-14 яшь тулгач кына велосипед белән олы юлга чыгарга мөмкин ;

- якынлашып килүче транспорт алдыннан юлны аркылы чыгарга ярамый;

-транспортны тукталышларда гына көтәргә.

* Юл йөрү кагыйдәләре
Бик күп төрле бит алар.
Һәрберсен яттан
белергә
Тырышыгыз, балалар!

